**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**06.09.2019** **№ 1519**

**Балигъ булмаганнарның опекуннары һәм попечительләре булырга яисә Россия Федерациясе гаилә законнары белән билгеләнгән башка формада ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен тормышка ашыручы оешмаларның эшчәнлеген контрольдә тотуны тормышка ашыру тәртибе турында Нигезләмәне раслау турында**

“Опека һәм попечительлек турында”, 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлекне тормышка ашыруның аерым мәсьәләләре турында”, 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы Карары белән расланган, мәгариф оешмалары, медицина оешмалары, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмалары, яки башка оешмалар тарафыннан, шул исәптән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмалары тарафыннан балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек органнарының аерым вәкаләтләрен тормышка ашыру Кагыйдәләренең 5 пункты нигезендә, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен бирү турында”, 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Расларга:

Балигъ булмаганнарның опекуннары һәм попечительләре булырга яисә Россия Федерациясе гаилә законнары белән билгеләнгән башка формада ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен тормышка ашыручы оешмаларның эшчәнлеген контрольдә тотуны тормышка ашыру тәртибе турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

Балигъ булмаганнарның опекуннары һәм попечительләре булырга яисә Россия Федерациясе гаилә законнары белән билгеләнгән башка формада ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен тормышка ашыручы оешмаларны планлы тикшерүләр графигы (2 нче кушымта).

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Сабирҗанов Р.Р.ка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

1 нче кушымта
«Расланган»
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль
районы башкарма комитеты
карары белән
06.09.2019 № 1519

**Балигъ булмаганнарның опекуннары һәм попечительләре булырга яисә Россия Федерациясе гаилә законнары белән билгеләнгән башка формада ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен тормышка ашыручы оешмаларның эшчәнлеген контрольдә тотуны тормышка ашыру тәртибе турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Әлеге Тәртип "Опека һәм попечительлек турында", 2008 елның 24 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлекне тормышка ашыруның аерым мәсьәләләре турында", 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы Карары белән расланган, мәгариф оешмалары, медицина оешмалары, социаль хезмәтләр күрсәтү оешмалары, яки башка оешмалар тарафыннан, шул исәптән ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар оешмалары тарафыннан балигъ булмаган гражданнарга карата опека һәм попечительлек органнарының аерым вәкаләтләрен тормышка ашыру Кагыйдәләренең 5 пункты һәм Россия Федерациясе Мәгариф Министрлыгының 2015 елның 13 мартындагы 235 номерлы Боерыгы белән расланган ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган баланы үз гаиләсенә тәрбиягә алырга теләгән затларны әзерләү буенча эшчәнлекне оештыру һәм тормышка ашыру Тәртибенең 24 пункты нигезендә эшләп чыгарылган һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы тарафыннан (алга таба – опека һәм попечительлек органы) балигъ булмаганнарның опекуннары яки попечительләре булырга яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә Россия Федерациясенең гаилә законнарында билгеләнгән башка рәвешләрдә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлап алу һәм әзерләү буенча оешмалар эшчәнлегенә контрольлек итү вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгели (алга таба – опекуннар булырга теләк белдергән граажданнарны сайлау һәм әзеләү буенча вәкаләтләр).

1.2. Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 18 маендагы 423 номерлы карарын тормышка ашыру турында", 2009 елның 14 сентябрендәге 334 номерлы боерыгы белән

билгеләнгән, опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзеләү буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру буенча оешмаларның эшчәнлеген контрольдә тоту Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты тарафыннан тормышка ашырыла.

1.3. Опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзеләү буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру буенча оешмаларның эшчәнлеген контрольдә тоту әлеге оешманың эшчәнлеген тикшерүләр уздыру аркылы тормышка ашыру тора.

## 2. Опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзеләү буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру буенча оешмаларның эшчәнлегенә тикшерү уздыру регламенты

2.1. Опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру буенча оешмаларның эшчәнлегенә тикшерү Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органының вәкаләтле вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) тарафыннан, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында”, 2008 елның 20 мартындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.1. Опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзеләү буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру буенча оешмаларның эшчәнлегенә тикшерү Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органының бер вәкаләтле вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) яки опека һәм попечительлек буенча аерым дәүләт вәкаләтләрен башкаручы икедән дә ким булмаган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты муниципаль хезмәткәрләреннән торган, шуларның берсе комиссия рәисе булган комиссия тарафыннан уздырылырга мөмкин.

2.2. Опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзеләү буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру буенча оешмаларның эшчәнлеген тикшерү планлы һәм планнан тыш булырга мөмкин.

2.2.1. Планлы тикшерү Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты тиешле календарь елга төзегән һәм карар белән расланган тикшерүләр планына кертелгән тикшерү булып тора.

2.2.2. Бер оешманы планлы тикшерү бер елга бер мәртәбәдән еш уздырылмый, балигъ булмаган гражданнарның опекуннары яки попечительләре булырга яисә ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калаган балаларны гаиләгә тәрбиягә алырга теләгән гражданнарны әзерләү узу өчен җибәрү шартнамәсе бирелгән очракта.

2.2.3. Планлы тикшерү оешманың урнашкан һәм эшчәнлекне тормышка ашырган урыны буенча уздырыла (урынга чыгып тикшерү).

2.3. Тикшерүләр планына кертелмәгән тикшерү планнан тыш тикшерү дип атала.

2.3.1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының опека һәм попечительлек органы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты карары нигезендә түбәндәге очракларда планнан тыш тикшерү үткәрә:

- оешма тарафыннан опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга карата шикаятьләр белән гражданнарның мөрәҗәгатьләре;

- дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, башка оешмалардан һәм гражданнардан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда оешма эшчәнлегендә гамәлдәге законнарны бозу турында мәгълүмат керү.

Планнан тыш тикшерү әлеге пунктта күрсәтелгән очраклар килеп туган очракта чикләнмәгән тапкыр урынга чыгып яисә урынга чыгмыйча үткәрелә

2.4. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген тикшерүне үткәрү максатларында Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) яисә комиссия әгъзалары түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган тикшерү үткәргәндә хокуклы түгел:

- әлеге вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга кагылмаган гамәлдәге законнар таләпләренең үтәлешен тикшерергә;
- тикшерү предметына карамаган документлар, мәгълүматлар бирүне таләп итәргә;
- әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тикшерүне үткәрү срокларын арттырырга.

2.5. Опекун булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча оешма эшчәнлеген тикшерүне үткәрү максатларында вазыйфаи зат (муниципаль хезмәткәр) түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган тикшерү үткәрү турында хәбәрнамә җибәрүне тәэмин итә:

- тикшерү формасы турында (урынга чыгып, урынга чыгмыйча гына);
- тикшерү рәвеше турында (планлы, планнан тыш);
- тикшерүне үткәрү вакыты турында (башлану һәм тәмамлану датасы);

Тикшерү уздыру турында мәгълүмат хаты оешмага, тикшерү башланганчыга кадәр 3 (өч) көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2.6. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәр) яисә комиссия әгъзалары хокуклы:

- оешманың вазыйфаи затларыннан тикшерү максатына ирешү өчен тикшерелә торган периодта документлар (мәгълүматлар) соратырга һәм аларгы, шулай ук тикшерү барышында килеп туа торган мәсьәләләр буенча язма һәм телдән аңлатмаларны да;

- тикшерү предметына кагылышлы документларның тикшерү материаллары белән танышу өчен күчермәләрен алуны гамәлгә ашыралар.

2.7. Урынга чыгып тикшерү уздыруның (урынга чыгып тикшерү) гомуми срогы 2 (ике) көннән дә арта алмый.

2.8. Урынга чыгып тикшерү тәмамланганнан соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча оешманың Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты вазыйфаи зат (муниципаль хезмәткәре) яисә комиссия тарафыннан өйрәнелгән материаллар, документлар һәм аңлатмалардан чыгып чыгып тикшерү акты төзелә.

2.8.1. Тикшерү акты кәгазьдә ике нөсхәдә төзелә.

2.8.2. Тикшерү актында түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

- тикшерү үткәрү көннәре санын күрсәтеп, тикшерү актын төзү датасы, урыны һәм вакыты турында;
- тикшерү төре һәм формасы турында;
- Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты карарының аның нигезендә тикшерү үткәрелгән датасы һәм номеры турында;
- тикшерү үткәрелгән оешманың исеме турында;
- тикшерү үткәрүче Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яисә комиссия әгъзалары турында;
- тикшерү үткәрү өчен оешма тарафыннан тәкъдим ителгән (тәкъдим ителмәгән) документлар (мәгълүмат) турында;
- оешма эшчәнлегендә опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне тормышка ашырганда ачыкланган хокук бозулар фактлары турында;
- оешма тарафыннан аның эшчәнлегендә ачыкланган хокук бозуларны һәм кимчелекләрне тикшерү тәмамлану датасына опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча төзәтү турында;
- тикшерү нәтиҗәләре турында гомумиләштерелгән мәгълүмат һәм нәтиҗәләр;
- оешма җитәкчесен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштыру яки танышудан баш тарту турында мәгълүматлар.

2.8.3. Тикшерү акты Татарстан Республикасв Биектау муниципаль районы башкарма комитеты вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яисә комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана. Аерым комиссия әгъзалары тарафыннан тикшерү актына кул куеп булмаган очракта, билгеле имзаның булмау сәбәбе турында тамга куела.

2.8.4. Тикшерү актына тикшерүгә кагылышлы документлар яки аларның күчермәләре, шул исәптән оешманың вазыйфаи затларының ачыкланган бозулар өчен җавап бирүче аңлатмалары теркәлә.

2.8.5. Тикшерү актының бер нөсхәсе оешма җитәкчесенә башкарма комитет җитәкчесе тарафыннан расланганнан соң 5 эш көненнән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2.9. Урынга чыкмыйча тикшерү Татарстан Республикасв Биектау муниципаль районы башкарма комитеты вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яисә комиссия әгъзалары тарафыннан булган документларны, шулай ук оешмалардан

соратыла һәм алына торган документларны, оешма вазыйфаи затларының аңлатмаларын карау аркылы тормышка ашырыла.

2.9.1. Оешма җитәкчесе, опекуннар булырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча вәкаләтләрне тормышка ашыру буенча оешмаларның эшчәнлегенә кагылган барлык соратыла торган документларны да, тикшерү уздыру турында мәгълүмати хатта күрсәтелгән срокта тәкъдим итәргә тиеш.

2.9.2. Урынга чыкмый уздырыла торган тикшерү нәтиҗәләре буенча башкарма комитет тарафыннан тикшерү нәтиҗәләре буенча белешмә әзерләнә. Белешмә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты вазыйфаи заты (муниципаль хезмәткәре) яисә комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана, Татарстан Республикасв Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан килештерелә. Белешмә оешмага заказлы хат белән, аны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты Җитәкчесе тарафыннан килештергән көннән соң 3 (өч) көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

2 нче кушымта
«Расланган»
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль
районы башкарма комитеты
карары белән
06.09.2019 № 1519

**Балигъ булмаганнарның опекуннары һәм попечительләре булырга яисә Россия Федерациясе гаилә законнары белән билгеләнгән башка формада ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны гаиләгә тәрбиягә алырга теләк белдергән гражданнарны сайлау һәм әзерләү буенча опека һәм попечительлек органының аерым вәкаләтләрен тормышка ашыручы оешмаларны**

**ТИКШЕРҮ ПЛАНЫ**

| Тикшерүләрнең периодиклыгы | Тикшерү уздыру ае | Тикшерү уздыру датасы | Тикшерү уздыру срогы |
|---|---|---|---|
| Елга 1 мәртәбә | октябрь | Айның икенче атнасы | 1 көн |